КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 4 сентябрь г.Казань № 730

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство буйсынуындагы кайбер типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының ведомство буйсынуындагы кайбер типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче, 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче, 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче, 2013 ел, 11 май, 313 нче, 2013 ел, 29 июнь, 455 нче, 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче, 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче, 2014 ел, 28 май, 362 нче, 2014 ел, 25 август, 613 нче, 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы, 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче, 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче, 2015 ел, 4 август, 565 нче, 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче, 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче, 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче, 2017 ел, 18 май, 292 нче, 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче, 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы, 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче, 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче, 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче, 2018 ел, 26 апрель, 293 нче, 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче, 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче, 2019 ел, 13 июль, 578 нче, 2019 ел, 28 август, 730 нчы, 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче, 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче, 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы, 2020 ел, 28 май, 433 нче, 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы, 2020 ел, 8 июль, 568 нче, 2021 ел, 4 февраль,

54 нче, 2021 ел, 26 июль, 645 нче, 2021 ел, 16 август, 737 нче, 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче, 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы, 2022 ел, 30 май, 499 нчы, 2022 ел, 20 июнь, 587 нче, 2022 ел, 15 июль, 683 нче, 2022 ел, 12 август, 797 нче, 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче, 2022 ел, 20 сентябрь, 1018 нче, 2022 ел, 11 октябрь, 1093 нче, 2022 ел, 8 ноябрь, 1184 нче, 2022 ел, 21 ноябрь, 1249 нчы, 2023 ел, 21 февраль, 171 нче, 2023 ел, 10 август, 968 нче, 2023 ел, 25 сентябрь, 1183 нче, 2023 ел, 1 ноябрь, 1390 нчы, 2023 ел, 18 ноябрь, 1487 нче, 2023 ел, 27 декабрь, 1696 нчы, 2024 ел, 10 апрель, 247 нче, 2024 ел, 11 июнь, 419 нчы, 2024 ел, 17 июнь, 431 нче, 2024 ел, 15 август, 659 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Республика башкарма хакимият органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктындагы таблицадан соң ундүртенче абзацка «өлкән медицина технологы»,» сүзләреннән соң «ашыгыч медицина ярдәме фельдшеры»,» сүзләрен өстәргә;

1 нче таблицаның «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме, «гомуми практика шәфкать туташы (гомуми практика медицинасы браты)», «паллиатив медицина ярдәме буенча шәфкать туташы (паллиатив медицина ярдәме буенча медицина браты)», «профилактика буенча шәфкать туташы (профилактика буенча медицина браты)», «медицина реабилитациясе буенча шәфкать туташы (медицина реабилитациясе буенча медицина браты)», «белем алучыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча шәфкать туташы – белгече (белем алучыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча медицина браты – белгече)», «медицина статистигы», «медицина профилактикасы кабинеты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы (медицина браты))» бүлеге исеменә «, «ашыгыч медицина ярдәме фельдшеры» сүзләрен өстәргә;

3 нче таблицаның «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме, «гомуми практика шәфкать туташы (гомуми практика медицинасы браты)», «паллиатив медицина ярдәме буенча шәфкать туташы (паллиатив медицина ярдәме буенча медицина браты)», «профилактика буенча шәфкать туташы (профилактика буенча медицина браты)», «медицина реабилитациясе буенча шәфкать туташы (медицина реабилитациясе буенча медицина браты)», «белем алучыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча шәфкать туташы – белгече (белем алучыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча медицина браты – белгече)», «медицина статистигы», «медицина профилактикасы кабинеты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы (медицина браты))» юлының 1 графасына «, «ашыгыч медицина ярдәме фельдшеры» сүзләрен өстәргә;

4 нче таблицаның «Урта медицина һәм фармацевтика белемле белгечләр вазыйфалары» юлының «Һөнәри квалификация төркеме исеме» графасына «, «ашыгыч медицина ярдәме фельдшеры» сүзләрен өстәргә;

4.3 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләренә, ведомство бүләкләренә ия булган өчен 51 нче таблицада китерелгән өстәмә түләү күләме;»;

сигезенче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның мактаулы хезмәткәре» күкрәк тамгасы булган өчен өстәмә түләү Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

51 нче таблицада:

3 графаның исеменә «, «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның мактаулы хезмәткәре» күкрәк тамгасы» сүзләрен өстәргә;

«Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме, «гомуми практика шәфкать туташы (гомуми практика медицинасы браты)», «паллиатив медицина ярдәме буенча шәфкать туташы (паллиатив медицина ярдәме буенча медицина браты)», «профилактика буенча шәфкать туташы (профилактика буенча медицина браты)», «медицина реабилитациясе буенча шәфкать туташы (медицина реабилитациясе буенча медицина браты)», «белем алучыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча шәфкать туташы – белгече (белем алучыларга медицина ярдәме күрсәтү буенча медицина браты – белгече)», «медицина статистигы», «медицина профилактикасы кабинеты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы (медицина браты))» һөнәри квалификация төркеме» юлының 1 графасына «, «ашыгыч медицина ярдәме фельдшеры» сүзләрен өтәргә;

6 нчы таблицадан соң икенче абзацка «өлкән медицина технологы»,» сүзләреннән соң «ашыгыч медицина ярдәме фельдшеры»,» сүзләрен өстәргә;

5.3 пунктның сигезенче абзацында «вазыйфаи окладның кимендә 4 проценты» сүзләрен «нигез окладының кимендә 4 проценты» сүзләренә алмаштырырга;

7.11 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT_{dnv} = \sum_{i_1=1}^{m_1} (KPO_{st_n} \times D_{gg} \times T_n \times (\frac{O_d}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d})) \times 0,5 + \sum_{i_1=1}^{m_1} (KPO_{sp_n} \times D_{gg} \times \times T_n \times (\frac{O_d}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d})),»;$$

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең, мәгариф хезмәткәрләренең, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең III бүлеге нигезендә кабул ителә торган вазыйфаи оклады;»;$O_d$

7.12 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«FOT_{dpd} = \sum_{i_2 = 1}^{m_2} (KPO_{st_p} + KPO_{sp_p}) \times (\frac{O_d}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d}) \times$$
$$\times D_{pg} \times T_{pd} + \sum_{i_2 = 1}^{m_2} ((KPE_{ambp} \times (\frac{SZP}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d}) \times D_{pg} \times T_{pd}) + (KPE_{ambp} \times (\frac{O_d}{D_{schrd}} \times \frac{1}{T_d}) \times$$
$$\times D_{pg} \times T_{pd})),»;$$

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләрнең, мәгариф хезмәткәрләренең, фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләренең, Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмаларының авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең әлеге Нигезләмәнең III бүлеге нигезендә кабул ителә торган вазыйфаи оклады;»;$O_d$

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтаның 105 юлының 6 графасына «, 161» саннарын өстәргә;

әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасының 106 юлының 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шешкә каршы дару терапиясе бүлеге»;

әлеге Нигезләмәгә 13 нче кушымтаның 33 юлының 3 графасына «, 161» саннарын өстәргә;

әлеге карар белән расланган эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләрнең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре, республика башкарма хакимият органнары карамагындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы буйсынуындагы аерым типик булмаган учреждениеләр белгечләре һәм хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 5.4 пунктының икенче абзацында «вазыйфаи окладның кимендә 4 проценты» сүзләрен «нигез окладының кимендә 4 проценты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин